**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 декабрендәге 5120 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 22 октябрендәге 2761 номерлы карары белән расланган**
**Ильич урамындагы «Юдино» территориясенең бер өлешен**
**планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Әзерләнүе вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү кагыйдәләрен раслау, территорияне планлаштыру документларын раслау, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документациянең яисә аның аерым өлешләрен юкка чыгару, мондый документациянең аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау турында карар кабул итү турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын раслау турында»гы карарына таянып **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 22 октябрендәге 2761 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 мартындагы 953 номерлы һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 3554 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Ильич урамындагы «Юдино» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына,

аның аерым өлешләрен әлеге карарның кушымтасы нигезендә раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 10 декабрендәге
5120 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 22 октябрендәге 2761 номерлы карары белән расланган Ильич урамындагы «Юдино» территориясенең бер өлешен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

Территорияне планлаштырып үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәдә «Торак фонды һәм халык» таблицасының 5 юлында «6-10» саннарын «7-11» саннарына алмаштырырга.

______________________